# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Көчек торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**25.11.2022** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Көчек торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2022 елның 25 ноябрендә 09:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Көчек пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Түбән Көчек торак пункты урамнарын кардан чистарту.
2. Түбән Көчек торак пункты урамнарына вак таш сатып алу һәм һәм түшәү.
3. Түбән Көчек торак пункытында К.Маркс һәм Тукай урамнары буенча чокыр эшләрен башкару.
4. Халыкны су белән тәэмин итү (Түбән Көчек торак пунктында су белән тәэмин итү өчен ремонт, хезмәт күрсәтү, тирәнтен насос һәм башка материаллар сатып алу).
5.. Түбән Көчек торак пункытында сәүдә базары территориясенә койма тоту өчен материаллар сатып алу.
6. Урам утларын, электр товарларын сатып алу, урнаштыру, алыштыру һәм хезмәт килешүе буенча электрикка түләү.
7. Түбән Көчек торак пункытында үлән чабу өчен триммер һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу.
8. Түбән Көчек торак пунктында кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч һәм авария тудыручы коры яшел үсентеләрне кисү.
9. Җирлек чикләренә аншлаг кую.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 434 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 231 кеше, бу 53,2 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 231 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Көчек торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Көчек торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Түбән Көчек торак пункты урамнарын кардан чистарту.

2. Түбән Көчек торак пункты урамнарына вак таш сатып алу һәм һәм түшәү.

3. Түбән Көчек торак пункытында К.Маркс һәм Тукай урамнары буенча чокыр эшләрен башкару.

4. Халыкны су белән тәэмин итү (Түбән Көчек торак пунктында су белән тәэмин итү өчен ремонт, хезмәт күрсәтү, тирәнтен насос һәм башка материаллар сатып алу).

5.. Түбән Көчек торак пункытында сәүдә базары территориясенә койма тоту өчен материаллар сатып алу.

6. Урам утларын, электр товарларын сатып алу, урнаштыру, алыштыру һәм хезмәт килешүе буенча электрикка түләү.

7. Түбән Көчек торак пункытында үлән чабу өчен триммер һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу.

8. Түбән Көчек торак пунктында кеше тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч һәм авария тудыручы коры яшел үсентеләрне кисү.

9. Җирлек чикләренә аншлаг кую.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Авыл җирлеге башлыгы Р.А.НУРМӨХӘММӘТОВ